РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул.Ленина, д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

03.04.2026 — № 14

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының Җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында керемнәр турында белешмәләр урнаштыру мәсьәләләрен җайга сала торган 07.11.2012 №25, 21.08.2017 №21 карарларының үз кечен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 ел, №505-ФЗ Федераль законга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару өчен бирү турында» 07.11.2012 елгы №25 карары;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару ечен бирү тәртибен раслау турында», 21.08.2017 елгы №21 карары.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

Авыл җирлеге башлыгы — А.И.Биккинин